КУЛЪЯЗМА ПРОКЛАМАЦИЯ

1860 елларда патша хөкүмәте либераль реформалар башлап җибәрә. Җәмгыятьне яңарту эшенә керешкәндә, хөкүмәт империядә яшәүче халыкларның мәдәни үсешен, милли дәүләтчелек традицияләрен, геополитик факторларны исәпкә ала. Илдә гражданлык җәмгыяте нигезен булдыруга юнәлдерелгән реформалар Россия империясенең Европа өлешендә урнашкан иллегә якын губернасында башлап җибәрелә, аларда руслар — күпчелекне, башка милләт вәкилләре (татарлар, башкортлар, фин-угор халыклары һәм башкалар) — азчылыкны тәшкил иткән.

Реформаларның уңышы киң халык катлауларының белем дәрәҗәсенә, кадрлар булу-булмауга барып тоташа, чөнки төрле сословие вәкилләреннән торган үзидарә органнарын оештыру, җитештерү өлкәсендә исә техник казанышларга мөрәҗәгать итү күздә тотыла. Шуңа да нәкъ менә XIX йөзнең икенче яртысында укырга-язарга өйрәтү эше авыл җирләрендә киң җәелә. Укый-яза белү генә кешеләргә гражданлык хокукларыннан файдалану мөмкинлеге бирә, сәнәгатьне хәзерлекле эшче-хезмәткәрләр белән тәэмин итә. Шуңа күрә башлангыч, урта һәм югары белем бирүче уку йортлары ачуның XX гасыр башында тагы да зуррак масштаблар алуы табигый.

Европа илләрендәге тәртипләргә һәм кануннарга йөз тотып планлаштырылган реформалар Россия империясендә яшәүче барлык халыклар да дәүләт телен белергә тиеш дигән концепциягә корыла. 1860-1870 елларда оешкан яңа дәүләти һәм иҗтимагый оешмалар, институтлар эш кәгазьләрен фәкать бер телдә генә алып бара, кайбер губерна идарәләре каршында эшләп килгән тәрҗемәчеләр штатлары кыскартыла.

Яңалыкларны тормышка ашыруда төп шартларның берсе белем бирү системасын камилләштерү була. 1866 елны бу җаваплы һәм мөһим эш бер ел элек Синод* обер-прокуроры итеп билгеләнгән граф Д. А. Толстойга йөкләнә. Халык мәгарифе министры, Идел буе төбәгендәге мәктәпләр белән танышу максатында су юлы буйлап командировкага чыга. Аны биредә көн итүче татарларның, фин-угор халыкларының, Рус дәүләте составында 350 ел гомер итүләренә карамастан, чит йогынтыга бирелмичә яшәүләре гаҗәпкә калдыра. Сәяхәтнең нәтиҗәсе буларак, Идел-Урал төбәгендә (Казан уку-укыту округы территориясе)** һәм Таврия губернасында яшәгән җирле халыклар өчен хөкүмәтнең махсус мәктәп сәясәтен үткәрү программасы эшләнә. Тарихта ул «1870 ел 26 март кагыйдәләре» дип билгеле. Бер якта караганда, бу «Кагыйдәләр» крестьян сословиесенә караган рус булмаган халыкларга дәүләт телен өйрәтү программасы кебек күренә. Әмма биредә сәяси максатлар

* Синод (Правительствующий Синод) — Рус православие чиркәве эшләре белән шөгыльләнүче үзәк дәүләт органы.

** Казан, Самара, Әстерхан, Уфа, Сембер, Вятка, Сарытау губерналары.

EV_1_08.indb 196 13.05.2008 12:20:45

да күздә тотылган. Ул рус мәдәниятенә һәм дәүләтнең көнкүрешенә православие дине йогынтысының көчле булуы, хөкүмәтнең империядәге рус булмаган халыкларны «йотарга», ассимиляцияләргә омтылуы белән бәйле. Бу хакта документта ачыктан-ачык әйтелә: «Русиядәге мәгарифнең максаты — рус булмаган халыкларны киләчәктә рус халкына кушу»[1].

«Кагыйдәләр», халыкларны хөкүмәт мәктәпләрендә рус телендә укыргаязарга, математика нигезләренә өйрәтү һәм православие рухында тәрбияләү максатларын күздә тотып, Казан миссионеры Н. И. Ильминский эшләгән укыту системасын гамәлгә кертә. Ул система укытуның башлангыч чорында балаларның туган телен файдаланугa корылган була. Дәреслекләр һәм христиан дини китаплары татар, чуваш, мари һәм башка телләргә тәрҗемә ителеп, кирилл хәрефләре белән басыла.

Мөселман динендәге халыкларны уку-укыту эшендә дә шушы методика файдаланыла башлый, бары тик православие дине урынына ислам нигезләре өйрәтелә. Русча укыту ике төрле уку йортларында: рус-татар (рус-башкорт, рус-казакъ) училищеларында һәм мәктәп-мәдрәсә каршындагы рус классларында оештырыла. Аларны күзәтү вазифасы халык мәгарифе министрлыгы чиновниклары булган халык училищелары инспекторларына тапшырыла. «Кагыйдәләр»дә укыту өчен дәреслекләр бастыру киряклеге дә искәртелә. Укытучылар исә мөселманнар, алар җитмәгәндә, татарча яхшы белүче христианнар, руслар дип тәгаенләнә. Башта рус классларын ачу, тоту, укытучы һәм дин сабагын өйрәтүче муллага хезмәт хакы түләү авыл җәмгыятьләренә йөкләнә. Мәхәлләләр, икътисадый кыенлыкларны сәбәп итеп, аларны ачуга каршы чыга башлагач, хөкүмәт земство, шәһәр үзидарәсе финансларын файдаланырга рөхсәт бирә.

1870 елдан Идел-Урал төбәгендә яшәүче мөселман халыкларының милли мәгариф системасына рус телен предмет буларак кертү планлаштырыла. Яңа вазгыять «Кагыйдәләр»дә күрсәтелгән түбәндәге таләпләрдә бик ачык чагыла: «16 яшькә кадәр барлык мәдрәсә шәкертләре (булачак муллалар. — *И. З.*) мәҗбүри рәвештә рус классларында укырга тиешләр, һәм 1870 елдан башлап, яңа мәктәп-мәдрәсәләрне ачуга рөхсәт, аларда рус классы каралган очракта гына биреләчәк»[2].

«Кагыйдәләр» киләчәктә аерым категория мөселманнар өчен рус телендә укый-яза белү мәҗбүри булачак дип игълан итә. Шулар рәтенә дин әһеле вазифасына дәгъва итүчеләр, земство собрание (мәҗлес)ләре, һәм шәһәр үзидарәсе әгъзалары (гласныйлар), крестьян үзидарәсе вәкилләре (авыл старосталары, салым җыючылар, волость старшиналары, аларның ярдәмчеләре, волость идарәсе әгъзалары) кертелә.

Ни өчендер бу карар, башка кануннар кебек, тулысы белән кануннар җыентыгында басылмый. Әйтик, шушы «Кагыйдәләр»не раслаган 1870 ел 26 март патша указында документның эчтәлеге яктыртылмый, фәкать расланuы турында гына әйтелә. Нәтиҗәдә «Кагыйдәләр» мәктәп сәясәтен тормышка ашыручы яки шушы мәсьәләгә катнашы булган чиновниклар өчен кулланмага әверелә, ләкин киң җәмәгатьчелеккә вакытында барып ирешми.

Хөкүмәтнең яңа сәясәтен православие дин әһелләре игътибар белән күзәтә. Христиан динендәге рус булмаган халыкларга дәүләт телен өйрәтү программасын, югарыда аталган «Кагыйдәләр»нең бер өлешен эшләүдә миссионерлар турыдан-туры катнаша. Озак та үтми, «Известия по Казанской епархии»[3] исемле басмада Синодтан алынган «Кагыйдәләр»нең мөселманнарга кагылышлы өлеше дөнья күрә. Шулай итеп, мөселманнар яңалыкны дөньяви дәүләт оешмасыннан түгел, ә үзләре шикләнеп күзәтеп барган чиркәү басмасыннан белеләр. Бу яңалык татарлар күңеленә шик сала.

Инде хөкүмәтнең яңа мәктәп сәясәте буенча башкарган кайбер эшләрен дә санап үтик. Ильминскийның укыту системасы 1867 елда Казанда оешкан «Изге Гурий җәмгыяте» тарафыннан керәшен һәм мөселманлыкка кайткан керәшен авылларында һәм башка урыннарда ачылган миссионер башлангыч

EV_1_08.indb 197 13.05.2008 12:20:45

мәктәпләрендә кулланыла башлый. «Изге Гурий җәмгыяте» алып барган күпкырлы эшчәнлекнең максаты — керәшеннәргә мөселман йогынтысын киметү, исламга кайту хәрәкәтен туктату, алар арасыннан башлангыч мәктәп укытучылары, дин әһелләре, ә киләчәктә — мөселманнарны христианлыкка авыштыручы миссионерлар әзерләүдән гыйбарәт була. Бу вакытта Казан Россия күләмендә исламга каршы көрәш үзәге булып санала. 1854 елдан Казан рухани академиясе каршында илдәге бердәнбер мөселманлыкка каршы көрәш бүлеге эшләп килә (Н. И. Ильминский, А. А. Бобровников, Е. А. Малов, Н. П. Остроумов, М. А. Машанов кебек миссионерлар шушы бүлекне тәмамлый). 1885 елны Казанда Идел-Урал төбәге епархия җитәкчелегенең съезды уза, анда каралган мәсьәләләр арасында мөселманнарның җирле халыкларга йогынтысын киметү, аларны христианлаштыру һәм башкалар була[4].

1873 елдан Казан рухани академиясендә мөселманлыкка каршы көрәш бүлеген тәмамлаучыларның курс, диплом һәм магистрлык эшләре, чиркәү әһелләренә җиткерү максатында, «Миссионерский противомусульманский сборник: Труды студентов миссионерского отделения при Казанской духовной академии» исемле вакытлы басмада бастырыла башлый (аның 24 санының 22-се 1873-1899 елларга туры килә). Бу китаплар ачык сатуда булып, мөселманнар кулына барып ирешәләр. Аларда ислам диненә каршы материаллар басылганга, мөселманнарның рус чиркәвенә нәфрәте тагы да көчәя, ә патша хөкүмәтенә ышанычы кими.

Рус классларында һәм рус-татар училищеларында укытуны оештыру өчен, 1872 елны Уфада, 1876 елны Казанда татар укытучылар мәктәбе ачыла. 1874 елны мәктәп-мәдрәсәләр Халык мәгарифе министрлыгы күзәтүенә күчерелә, ягъни мөселман уку йортларына, хәлфәләрнең, дин әһелләренең укыту-тәрбия эшенә күзәтчелек итү хокукы, Диния нәзарәте кулыннан алынып, шушы министрлыкка тапшырыла. Казан уку-укыту округындагы мөселман уку йортларын контрольдә тоту эше махсус чиновник — татар, башкорт, казах мәктәпләре инспекторына тапшырыла. Бу вазифаны башкару өчен Казанга 1872 елны күренекле тюрколог В. В. Радлов чакырыла (ул 1884 ел азагына кадәр Казанда эшли, 1889 елны бу вазифа бетерелә). Авыл җирендә рус классларын, рус-татар училищеларын ачканда, еш кына полиция һәм чиновниклар халыкка көчле басым ясый: чөнки план үтисе, рапорт бирәсе бар, ә мәхәлләләрнең каршы килүе хакимиятнең ачуын кабарта.

Яңа вазгыять татарлар арасында хөкүмәт һәм земство керткән яңалыклардан шикләнүне көчәйтә. Шуның өстенә, чиновникларның дорфалыгы, авыл халкының һәр яңалыкка шәригать кушмый дип каравы аерым төбәкләрдә хакимият белән каршылыклар китереп чыгара. Император Александр IIнең киләчәктә мөселман дин әһелләренә рус телен белү кирәк булачагы турындагы 1888 ел 16 июль указына каршы Идел-Урал төбәгендә мөфтигә, патшага, эчке эшләр министрына мәхәлләләрдән, яңа канун кертү вакытын кичектерүне сорап, күмәк гаризалар, үтенечләр бирү кампаниясе башлана. 1889-1890 елларны башкаладан Казанга губерна мөселманнарының 350 гаризасы кире кайта. Петиция бирүнең оешкан төстә алып барылуы һәм киң колач алуы халык арасында таратылган кулъязма прокламацияләр белән дә бәйле була.

Биредә укучы игътибарына халык арасында таралган шундый кулъязмаларның берсе тәкъдим ителә. Аның төп нөсхәсе һәм русчага тәрҗемәсе Татарстан Республикасы Милли архивында саклана[5]. Русчага тәрҗемәсенең тагын бер нөсхәсе Санкт-Петербург шәһәрендәге Россия дәүләт тарих архивында да бар[6]. Прокламация 16 битле (8 куш бит), юллы ярты дәфтәргә язылган. Һәр битнең озынлыгы — 22 см, киңлеге — 18 см. 13 бит ике яклап, бер бит — бер яклап язылган, ә икесе буш калган.

Кулъязма салынган конвертның өске өлешенә «Ошбу әманәт тапшырылса иде Олуг Әтнә кантурында булгучы старшина Нәҗметдин Хисаметдин мәрхүм углына» дип язылган. Аста сул почмакта «Бирелде Казандан» диелгән.

EV_1_08.indb 198 13.05.2008 12:20:45

Конвертның арткы ягында бит почмаклары зур сургуч белән ябыштырылган. Сургучта нинди мөһер басылганы, анда ни язылганы укылмый. Һәрхәлдә, почта мөһере эзе юк. Моннан тыш, конвертның зур сургучлы почмаклары арасындагы битләр ачылмасын өчен, кечкенә сургуч ябыштырылган, һәммәсе дүртәү. Конвертка адресның русча язылмавы, сургучтагы мөһернең укылмавы аның почта аша түгел, ә юлаучы белән Олы Әтнәгә җибәрелүе һәм почта ящигына салынуы хакында сөйли. Бәлки пакетны алып кайткан кеше, узып барышлый волость идарәсенә кереп, анда Нәҗметдин Хисаметдиновны очратмыйча, конвертны идарә янындагы почта ящигына салып киткәндер.

Кулъязманың язылу датасы күрсәтелмәгән. 1900 елның 12 март көнне пакетны, Олы Әтнә волость идарәсе бинасы янындагы почта ящигыннан, волость писаренең ярдәмчесе алып керә. Шикләнеп, конвертны адресатның кулына бирмичә, бәлки ул килгәнне көтмичә, волость идарәсендә ача. Анда язылганнар белән танышкач, тиз арада земский начальникка һәм стан приставына хәбәр ирештерелә. Земский начальник, яңалыкның халык арасында таралуын теләмичә, кулъязманы тәрҗемә иттерми. Пристав исә кулъязманы Олы Мәңгәр волосте старшинасы Нәҗметдин Шәмсетдиновтан кыскача тәрҗемә ясатып ала. Яңалыкны ишеткән Казан өязе исправнигы, татарлар арасындагы хәлгә күзәтчелек итү, кирәк булса чара күрү өчен, шунда ук Олы Әтнәгә юнәлә.

Земский начальник пакетның пәйда булуын Олы Әтнәдә мулла Габдуллажан Габдрәкыйпов йортында кыш көне яңа ысул (ысуле җәдит) белән укыта торган мәктәп ачылуга, авыл халкының бер өлеше аңа каршы булуга бәйләп карый.

Казанда текстны русчага Казан укытучылар семинариясе мөгаллиме Н. И. Ашмарин тәрҗемә итә. Ул кулъязманы прокламация күчермәләренең бер нөсхәсе, тексттагы аңлашылмый торган урыннарны исә күчерүчеләр җибәргән ялгышлар дигән фикерен белдерә.

Прокламациянең авторын эзләү нәтиҗә бирми. Яшерен кулъязманы язучының Казан өязеннән булмавын раслап, өяз исправнигы 1900 елның 21 сентябрендә болай дип яза: «Автор брошюры должен быть лицо хорошо грамотное, интеллигентное, следившее за всеми правительственными распоряжениями, касавшимися магометан. В Атню брошюра могла попасть через Казань, куда выезжает много магометан из различных местностей России при поездках на Нижегородскую ярмарку...»[7].

Рус хөкүмәтенә дошмани тонда язылган кулъязманың авторларын фаразлап, Казан шәһәр полициясе мөселманнар арасында гыйлемле һәм шәригать юлында нык торучылар буларак билгеле, зур авторитетка ия кешеләрнең — бишенче мәхәллә мәчете имамы Габдулла Апанаев, ахун Мөхәммәтйосыф Сәгыйтов, бертуган Салиховларның, Галимҗан Галиев (Баруди) исемнәрен атый. Аларның шәһәр мәдрәсәләре каршында, күрше биналарда эшләүче рус классларын мәдрәсәгә кертмәү өчен тырышуларын, рус классларының шушы юл белән мәдрәсәгә кушылып, бербөтенгә әверелүеннән куркуларын бәян итә. Г. Галиевнең җәйге каникул чорында, Мәкәрҗә ярминкәсе вакытында, ел саен Казаннан башка шәһәрләргә сәяхәт кылуын билгеләп үтә. Габдулла Апанаевның исә, Беренче Россия страхование җәмгыяте әгъзасы сыйфатында губерна авылларында еш булуы, Казанда кунак йорты (постоялый двор) тотуы сәбәпле, билгеле шәхес икәнлеге ассызыклана. Фаразларны раслардлык фактлар табылмау сәбәпле генә, аларга карата бернинди дә чара күрелми[8].

Полициядән алынган мәгълүматларга таянып, Эчке эшләр министрына язган хатында Казан губернаторы югарыда аталган дин әһелләре хакында болай дип яза: «…смотрят на преподавание в медресах по звуковому методу не только русской, но и татарской грамоты как опасное нововведение, свидетельствующее о намерении правительства обратить в христианство мусульманскую молодежь»[9].

Прокламация өч бүлектән тора. Кулъязманың беренче һәм икенче өлеше бер почерк белән язылган. Өченче бүлекне башка кеше күчергән, текстны

EV_1_08.indb 199 13.05.2008 12:20:45

яңа биттән яза башлаган. Анысының карасы да сыйфатлырак. Бүлекләр төрле елларда төрле авторлар тарафыннан язылса кирәк. Соңгысы текстларда каршылыклы фикерләр булудан чамалана. Әйтик, икенче өлештә билгесез автор язылганны «Яхшы имамларга, яхшы кешеләргә, зинһар, укытып аңлата күр. Зинһар, саклан, надан мужикларга күрсәтмә, фетнә чыгарырлар. Йа, Рабби, үзең сакла, әмма муллаларга күрсәтеп, алар күргәч, күчереп алмак фарыздыр», дип яза. Беренче өлештә исә, киресенчә, прокламацияне күчереп алып, дин кардәшләргә таратырга, ләкин начальниклар белән муллаларга бирмәскә өндәлә.

Кулъязманың беренче өлеше 1889-1890 елларны, дин әһелләренә рус телен өйрәтүгә каршы җәелдерелгән петиция бирү кампаниясе вакытында, халык арасында таралган прокламацияләр белән охшаш. Биредә дә «Известия по Казанской епархии»дә басылган 1870 елгы «Кагыйдәләр»нең кыскача эчтәлеге бәян ителә, Е. Виноградовның «Противомусульманский сборник»та басылган «Метод миссионерской полемики против татар мухаммедан»[10] исемле хезмәтенең кереш өлешендәге муллаларны беренче чиратта чукындырырга чакырган, аннары мәхәлләдәге калган халыкны христианлаштыру җиңел булачак дип раслаган фаразлары кабатлана.

Билгесез автор дин кардәшләрен хөкүмәт ачкан уку йортларында түгел, ә репетитор яллап русча укырга-язарга өйрәнергә киңәш итә. Русча белгән кеше генә дәүләттәге хәлләрне аңлый, хөкүмәттән алдатмый һәм руслардан бәйсез яши, дип исбатлый. Шул ук вакытта автор мөселман авылларында рус уку йортлары, хәтта игенче өчен файдалы һөнәр училищелары ачуга да каршы чыгарга өнди. Ул халыкны һөнәр училищелары биналарының киләчәктә поплар тору урынына әвереләчәк, алар каршында чиркәү салыначак, дип куркыта. Училищеларны ачуга каршы торуның иң үтемле чара төсендә, мәхәлләнең һәм крестьяннарның җиргә хуҗа булу хокукыннан файдаланып, уку бинасы төзү өчен җир бирмәү күрсәтелә. Ул Россия хөкүмәтенең төрле төбәкләрдә мөселманнарга карата алып барган сәясәтеннән хәбәрдар. Шул исәптән, Кырым татарларының Төркиягә күченү сәбәпләрен дә аңлый. Кулъязмада хакимиятнең казакъ далаларында 1868 елдан башлап татарларга каршы үткәргән сәясәте дә җентекләп тасвирлана, күчмә халыкка йогынты ясамасыннар өчен, татарларны дин әһеле итеп билгеләмәү, эзәрлекләү телгә алына.

Документтагы Екатерина IIдән башлап XIX йөзнең уртасына кадәр патшалар һәм дәүләт түрәләре тарафыннан татарларга карата зарланырлык эшләр кылынмады, ягъни хөкүмәтнең дини һәм милли сәясәте мөселманнар өчен зыянсыз булды дигән фикер дә игътибарга лаек. Илдә миссионерлык хәрәкәтенең көчәюен автор Европада исламга каршы башланган сәясәтнең дәвамы итеп бәяли.

Әлбәттә, прокламациядә ялган хәбәрләр дә, халык арасында киң таралган имеш-мимешләр дә урын алган. Шуларның берсе — ир белән хатын мөнәсәбәтләренә православие кануннарын кертү, ягъни ир-атка икенче хатын алуны тыю, хатынны аерып җибәрү хокукын бетерү, ир һәм хатынны мөселман һәм христиан исемнәре белән язу. Шулай ук чукынган өчен 12 елга салым түләүдән азат итү хакындагы хәбәр дә чынбарлыкка туры килми (чукынгач, кеше дин кардәшләре яшәмәгән урынга күчсә, ул 3 елга салым түләүдән азат ителгән). Прокламациядә аталган, губерналарга миссионерлар җибәрү турындагы хөкүмәтнең 1885 елгы март ае карары да әлегә билгеле түгел.

Автор 1880 елларда хакимият коридорларында куерып киткән, Диния нәзарәтен ябу турындагы хәбәрдән дә мәгълүматлы булуын раслый. Себердә миссионерларның активлашуын телгә ала. Әйтик, Тубыл шәһәренә миссионер Е. К. Елисеевның килүен, аның татар авылларына барып, барлык кешеләр дә Адәмнән килеп чыккан, дин бер булырга тиеш, чын дин ул православие дине генә, хак дингә күчегез дип өндәп, исламга каршы язылган 83 һәм 64 битле ике брошюра* таратып йөрүе билгеле.

* Шуларның берсендә «Мухаммед большую часть своей жизни провел в распутстве с множеством блудных

EV_1_08.indb 200 13.05.2008 12:20:45

Бу мәгълүмат белән һәм патша исеменә жалоба-протест язуын сорап башта бохарчы хаҗи Т. Гаетмөхәммәдов, аннары Тубыл өязе Бәргер мәхәлләсе ахуны хаҗи А. Әнвәров 1901 елны Оренбург мөфтие Мөхәммәдьяр Солтановка мөрәҗәгать иткән булалар[11].

Прокламациянең беренче өлешен төзүче нинди чыганаклардан файдаланган? Хөкүмәтнең дини сәясәтенә бәйле мәгълүмат Диния нәзарәтендә казый булып торучы Казан губернасы муллаларыннан алынган булырга мөмкин (шуларның берсе үзе язмаган булса). Бу фикерне прокламациядә телгә алынган Диния нәзарәтенең секретаре Попов турындагы хәбәр, Диния нәзарәтенең Вятка земствосы һәм губернаторы, Оренбург генерал-губернаторы, Сарапул өязе училище советы белән язышуы турындагы төгәл мәгълүмат раслый. Моннан тыш, әлеге материалларның вакытлы матбугатта басылып чыккан булуы мөмкин.

Кулъязманың икенче бүлеге «Русиядә исламият галәһенә мөдахәләи рәсмия» дип атала. Монысы — безгә моңарчы билгеле булмаган текст. Биредә дәүләтнең мөселманнарга карата сәясәте бәян ителә. Беренче итеп земстволарның мөселман балаларына рус телен укыту инициативасына тукталына. Әйтергә кирәк ки, 1870 елгы «Шәһәр положениесе» нигезендә, милеккә ия һәм шәһәргә билгеле күләм салым түләүдән чыгып шәһәр думаларына сайлаулар оештырыла башлый. Нәтиҗәдә сайлаучыларның саны нык кими, үзидарә органына татарлар бик аз санда, анда да русча яхшы белгән сәүдәгәр яки вак алыш-биреш белән шөгыльләнүчеләр сайлана. Авыл төбәкләрендә оештырылган үзидарә органнарына исә, шәхси күчемсез милек хуҗаларыннан тыш, җирдән файдаланучы авыл мәхәлләләреннән да вәкилләр сайлау каралган була. Өязда яшәгән дворян, сәүдәгәр, мещан, крестьян вәкилләреннән торган мәҗлестә соңгылары, милләте нинди булуга карамастан, белем җитмәү сәбәпле, күпчелек очракта тыңлап кына утыра. Өяз земство мәҗлесенә авыл җәмгыятьләреннән сайланган татарлар, чуашлар, марилар һәм башкалар, русча белмәгән очракта, бик авыр хәлдә, образлы әйткәндә, телсез һәм чукрак хәлендә кала. Шуңа күрә мөселман балаларын рус теленә өйрәтергә кирәк дигән сүзләр земство мәҗлесләрендә күзәтелгән аяныч хәлне үзгәртү максаты белән, аларда катнашучы русча укый-яза белүче татарлардан һәм башка милләт вәкилләреннән ишетелә. Бу фикерләр, җирле үзидарә органы карары буларак, губернаторга, Диния нәзарәтенә җиткерелә. Кайбер земстволарның бу тәкъдиме хөкүмәт тарафыннан мөселманнар арасында рус телен таратуга юнәлдерелгән 1870 елгы «Кагыйдәләр» кабул ителгәнче үк яңгырый. Бу үзенчәлекне автор белә. Кулъязмада Вятка губернасы земство мәҗлесендә гласный Мирсәет Юнысовның татар балаларын русча укытырга кирәк дип белдерүе һәм бу хакта земстволың, губернаторның (1868 ел) Диния нәзарәте белән язышуы, Оренбург генерал-губернаторы Крыжановскийның таләбенә (1878 ел) каршы мөфти С. Тәвкилевнең, мәктәп-мәдрәсәләр Халык мәгарифе министрлыгы карамагында булу сәбәпле, Диния нәзарәтенә буйсынмыйлар дип белдерүе, шулай ук Сарапул өяз училище советы белән язышуы (1868 ел) телгә алына.

Икенче төп юнәлеш дип 1891 елдан дин әһеле (мәәззиннән кала) булырга теләгәннәр өчен рус телен белүнең мәҗбүри булуы атала. Автор фикеренчә, мулла кеше дини йолалар башкара, бу — аның төп вазифасы, ә рус телен белү ирекле булырга тиеш. Соңгы биш-алты елда муллалар арасында гарәп, фарсы телен яхшы белүчеләр азаюны ул рус телен белүнең мәҗбүрилеге белән аңлата: янәсе, шәкертләрнең Коръән телен өйрәнергә вакытлары калмый.

Дәүләтләр җимерелү, халыклар инкыйразының төп сәбәбе итеп автор җәмгыятьтә бердәмлек булмауны атый. Татар милләтенең хәлен күздә тотып, ул иң яман күренеш дип татарлар арасындагы таркаулыкны, бигрәк тә муллаларның үзара дошманлыгын күрсәтә. Дин әһелләрен төрле бозыклыклардан качарга, мәхәллә халкын изге эшләр-

женщин» дигән сүзләр дә бар (кара: РДТА, 821 ф., 8 тасв., 791 эш, 207 битнең арткы ягы).

EV_1_08.indb 201 13.05.2008 12:20:45

гә өндәп кыска нәсыйхәтләр бирергә өнди. Казан шәһәрендәге мөселманнар арасында да бердәмлек булмауны, чукыну очраклары күбәя баруны раслау өчен, «Нил» гәзитендә басылган язманы китерә.

Кулъязманың өченче өлешендә киләчәктә мәктәп-мәдрәсәләр белән идарә итү, аларда укыту-тәрбия эшен камилләштерүгә юнәлдерелгән программа тәкъдим ителә. Прокламациянең бу өлеше — татар тарих фәне өчен зур яңалык. Язмада хөкүмәт алып барган сәясәт, Диния нәзарәтен мәктәп-мәдрәсә эшләреннән читләштерү милләтнең киләчәгенә янаучы зур куркыныч буларак бәяләнә һәм, шушы хәлдән чыгу өчен, милли мәгариф системасының мөстәкыйльлеген көчәйтү, аны кабат Диния нәзарәте карамагына кайтару кирәклеге ассызыклана. Кулъязмада мөселманнарның үз уку йортларын заман таләпләренә җавап бирердәй итеп үзгәртү проекты да китерелгән.

ИСКӘРМӘЛӘР:

1. Аграрный вопрос и крестьянское движение в Татарии 50-70-х годов XIX в. – М., Л., 1936. – Ч. 1. – С. 285.
2. Там же. – С. 289-291.
3. Известия по Казанской епархии. – 1870. – 15 сентябрь. – № 18.
4. Заһидуллин И. К. Шовинизмның кайбер сыйфатлары // Татарстан. – 1996. – № 3. – Б. 44-46.
5. ТР МА, 1 ф., 6 тасв., 45 эш, 11-25 кгз.
6. Россия дәүләт тарих архивы (РД ТА), 821 ф., 8 тасв., 816 эш, 214-223 кгз.
7. ТР МА, 1 ф., 6 тасв., 45 эш, 43-43 кәгазьнең арткы ягы.
8. Шунда ук, 5, 44-45 кгз.
9. РД ТА, 821 ф., 8 тасв., 816 эш, 212 кәгазьнең арткы ягы.
10. Виноградов Е. Метод миссионерской полемики против татар мухаммедан // Миссионерский противомусульманский сборник. Труды студентов миссионерского противомусульманского отделения при Императорской Казанской духовной академии. – Казань, 1873. – Вып. I. – Ч. 2. – С. 7.
11. РД ТА, 821 ф., 8 тасв., 791 эш, 205, 207-207 кәгазьнең арткы ягы.

Илдус Заһидуллин,
тарих фәннәре докторы

Русия хөкүмәтенең ислам диненә һәм мөселманнарга карата сәясәтен яктырткан һәм аңа каршы тору ысулларын тәкъдим иткән татарча аноним прокламациядән өзек

Казан губернасының епархиясе, ягъни православный мәзһәблекләрнең хәбәрләре җөмләсеннән 1870 нче сәнәдә 15 нче сентябрьдә 18 нче номерда министрларның киңәше илән 8 нче пункда 2 нче фасылда яңа мәктәп һәм мәдрәсәләр урысча язу вә һәм уку укыту классыны мөселманнар хәраҗатына булмаган сурәттә һәм мәдрәсә вә мәктәпләрне народный училищеның инспекторы тәхте тәсаррыфына салып, шул ук мәдрәсә вә мәктәпләрдәге русский классның, ягъни русча укытылуның тәсаррыфы народный училищелар кулына вә тәдбиренә алынмый торып, мәдрәсә вә мәктәбләр ачылмау хосусында, шуның өчен мөселманларны абразавайт итү (ягъни каралтырга) мөмкин булыр шул вакытта, кайчан урыс теле анлар арасына сачылса һәм шуның охшашлы иҗтиһадларымызны сарыф кылып, анларның күңелләренә яңа эшләр тугдырырга. 1 нче статья: шул сурәтдә мөселманларны урыс язуы белергә вә рус гыйлемен белергә котыртып, ошбундан бераз еллардан соң закон чыкарырга тиеш була. Мөселманларның духовный должностена керергә теләүчеләр мәзкүр должностька сайлана алмаслар, әгәр дә бер мәгълүм микъдары кирәкле кадәр русча телне белгәнлекләрендән свидетельстволары урысча язу вә уку белү хосусында булмаса һәм арифметиканың әүвәлге дүрт действосын белү хосусында булма-

EV_1_08.indb 202 13.05.2008 12:20:46

са, янә дә мөселманларның мәктәб вә мәдрәсә гыйлемләре белү хосусында. Шул аларга рус язуны белү тәмам илтизам кылынып беткәч, 2 нче Таврический духовный управление, ягъни Кырымның тәхте тәсаррыфында торгучы мөселманларга да ошбу законны тәдбир кылырга мөмкин. Ул вакытта Кырым халкындагы духовный званиедән сайлана торган имамларны бетереп, простой халыклардан да сайлау мөмкин икәнлек порядкасын кую тиеш. 3 нче сәбәбе шул, бер вакытдан соңрак бу тугърыда закон вә низам куеп, мөселманлардан ихтимал сайларга городской яки общественный должностька яки кәнсәләренә һәм управлениеләр должностена рус телендә уку-язу белү хосусында шәһадәтнамәләре булу хосусында көн вә числасы булыр, вәгъдәсе булыр. Министр внутренний делның киңәше берлән рус язуы белү хосусындагы андый свидетельстволары бирелер. Өяз училищеларының һәм народный училищеларының инспекторы тәдбире берлә булыр. Мөселман диненә каршылыкны касыд кылып, ягъни миссионер нәсрани диненә өндәүчеләрнең җыеп язган кенәгәләрендән нөсхә вә копия шул мәзкүр нәсараның ыстуденларының эше. Мәзкүр хосуста эш Казанның духовный академиясендән әүвәлге тасниф 1873 нче елда иң әүвәл без бу тугрыдагы, ягъни мөселманларны үз динемезгә өндәүлек порядкасыны кылырга кирәк. Муллаларны үземезнең юлымызга салырга, аның өчен муллалар ничек булса кара халык, шулай булачагы мәгълүм. Галимләр кара халыкның мөсәлләм булган кешеләре, башка халыкка караганда, динне һәм ниндәен дин кирәклеген яхшырак таный торган кешеләр. Шушы җул берлән миссионер булган кешегә тиеш эшне муллалардан башларга, ягъни муллалар һәм галимләр мөселманларны дингә өндәүгә, кайсыларына кара халык мөсәлләм булырлар һәм кайсылар дине Исламга үгрәтү хосусында гадәттән тыш примерлар вә мисаллар күрсәтәләр. Гадәттән тыш эшләр күрсәтү мөмкин һәм дәрвакыйг шул көенчә муллаларны авыштыргач, аны кара халыклар күреп әйтерләр: бу безнең галимләремез, галим кешеләремез белмәенчә яңа христиан динене кабул кылмый торганлардыр, без дә яңа дингә керәек дип кабул кылырлар. [...]* Алла сакласын. Шушы җул берлән эшне йөрткәч, күп мөселманларны христиан диненә мөмкин диеп өмид иттеләр. Аллаһы Тәгалә хәзрәте өмидләрен кисеп, дине Исламга куәт вә носрәт бирсен, амин** [...]***.

Әй, мөэминләр, ошбу язган сүзләрне укып, аңар миннән соң мөэмин мөселманларга күчереп алмаенча, хакимләргә яки хәзрәтләргә биреп заигъ кылмагызлар, чөнки моннан мөкаддәм сезләргә үтенеп тәнбиһ булыңыз. Бер фәкыйрь Мәкәржә ярминкәсендә**** мөселманлар берлән бер мәслихәттә булып, бән ихтыярлы булдым. Саратау вә Петропавел вә Семипалат, Касим һәм Булман буендагы ахунларның әмере илән сезләргә язып белдердек шуны*****. 1884 нче сәнәдә 2 нче гыйнварда падишаһдын фәрманы галиләре булгандыр******, высочайший повеления, мәмләкәттә булган мөселманларны урыс диненә кертергә, әлгыязе биллаһи тәгалә, шуның өчен өяздә тәгаенләнгән миссионер ләкабы илә поплар куелырга, мөселман илләрендә йир сатып алып (яки бер-бер хәйлә илә приговор берлән

* Гарәп телендәге дога төшерелеп калдырылды (биредә һәм алга таба И. Заһидуллин аңлатмалары).

** Е. Виноградов хезмәтенең керешендә болай дип фаразлый: «Предлагаемый нами метод миссионерской полемики, как с первого раза заметить можно, направлен преимущественно против мухаммеданских мулл и вообще против более или менее ученых и образованных мухаммедан, как людей сознательно и убежденных в истине и божественности своей веры. Причина в том следующая. Муллы и вообще люди ученые в мухаммеданстве пользуются величайшим уважением и почтением: как к людям ученым, знающим веру лучше и более, нежели другие, к ним питают все полную доверенность. По одному этому миссионер обращение должен начать с мулл и вообще образованных мусульман, пользующихся между татарами особенным уважением и почтением. Сила примера и вообще оказывает невиданное действие она может и должна оказать в мухаммеданстве. Неученый, увидев своего муллу, обратившимся к христианству, будет рассуждать так: «если уже мулла, человек ученый, лучше других знающий веру, оставил мухаммеданство, и принял веру новую — христианскую, то наверно, новая, христианская вера лучше и есть святая». По обращении к христианству муллы можно уже надеяться на обращение весьма многих мухаммедан его прихода» (см.: Виноградов Е. Метод миссионерской полемики против татар мухаммедан // Миссионерский противомусульманский сборник. Труды студентов миссионерского противомусульманского отделения при Императорской Казанской духовной академии. – Казань, 1873. – Вып. I. – Ч. 2. – С. 7).

*** Гарәп телендәге дога төшерелеп калдырылды.


**** Сату-алу күләме, катнашкан сәүдәгәрләр һәм халык саны буенча Бөтенрәсәй ярминкәсе исемен йөрткән Түбән Новгород шәһәре янындагы ярминкә халык телендә Мәкәржә ярминкәсе исеме белән аталган. Мәкәржә монастыре янындагы бу ярминкә 1816 елгы янгыннан соң Түбән Новгород янына, Ока елгасы белән Идел кушылган урынга күчерелә. XIX йөзнең икенче яртысында биредә ел саен берничә йөз татар сәүдәгәре һәм приказчигы сәүдә итә. Ярминкә 15 июльдә ачылып, бер ай дәвам иткән.

***** Биредә сүз 1889 яки 1890 елгы сәүдә сезоны турында бара.

****** Патшаның 1884 ел 2 гыйнвар указы да бутап язылганга охшый. Биредә императорның 1882 ел 5 февраль указы нигезендә инспекторларга мәктәп-мәдрәсәләрдә контроль урнаштыру, тикшерүләр үткәрү турындагы указ күздә тотылмый микән. 1883 елда Казанда бу указны тормышка ашырырга омтылу көчле каршылыкка очрый.

EV_1_08.indb 203 13.05.2008 12:20:46

җир сорап алырлар, зинһар, сакланыңызлар приговор һәм җир бирмәктән), олуг йирдә йорт салып, карарланыр өчен ач-ялангачларны дингә өндәр өчен шул хәйлә илә рус диненә унике ел ясак акчасыннан котыла дип. Әмма белмәк кирәк, ул ясак акча да бетеп, гавам хасс үлеп дигән иде. Барын да ялган сәбәп әйтәдер, дингә һәвәсләнсенләр өчен дип. Ул поплар карар кыла торган урынлар исемләнер ремесленный училищелар дип, ягъни осталык һәм һөнәрләр мәдрәсәсе дип. Анда үгрәнерләр төрле кул һөнәрләре яшь балалар ярлыларның. Ул балаларның ата вә аналарыны анда кертерләр хезмәткәрлеккә



Кулъязма прокламациянең беренче бите. ТР МА, 1 ф., 6 тасв., 45 эш, 24 кгз.

дип, бик кыйммәт хаклар биреп. Ул бәндәләрнең үзләрен һәм бәгъзесен заглафи* исемле булыр яки аграрнуминурым** дип әйтерләр. Әмма саклангайсыз урын сатмаклыктан һәм балаларыңызны бирмәклектән. Ул заботаларга яки ул училищелардан смотритель, ягъни назыйр, помощник, ягъни наибләргә барчасы поп женесендән поп булырлар. Мәгәр муллалар илә булырлар дигән, мөселманнар шик кертмәсен өчен. Шул эшкә падишаһдин высочайший повеление бирелгән. Шул эш өчен Эстәрлетамак өязендә Габдулла дигән ахмак биш йөз дисәтинә йирне һибә кылган. Хашакәлла, мөселманчылык канда калды. Падишаһ бу эштә мәслихәт күреп, шул ук бу эшләрне тәхкыйк күреп, белеп әйтәмен, йыглап-йыглап үтендек: диндә таййар булып, балаларыгызны саклагызлар кяфер мәкерендин, аңа ярдәм кылмагыз, урын бирмәгез, мөмкин кадәре мәнегъ кылыгыз. Бу тугрыда бер булып сезләргә әйтмәсәк, игълам кылмасак, без гөнаһкяр улырмыз, фетнә өчен язмадык. Бәлки кяфер мәкереннән агяһ улыңыз дип яздык. Тәхкыйк, мөселманларны чукындырырга указы бар, бирелгән. Алла, Алла! Шуның өчен юашлык, акрынлык илә эш кылалар һәр төрле

* Документта шулай.
** Документта шулай.

EV_1_08.indb 204 13.05.2008 12:20:46

хәйлә илә. Себер йирләрендә поплар мөселманларны авылларында заһир крест күтәреп, батыйль дингә өндәп, Кавказ йортында күп йортны чукындырдылар, Алла, йа рәсүлүлла. Төркестан вилайәтендә көчләп ясадылар. Надан түрәләргә кызыл чикмән, көмеш иярләр биреп, ярлыларны куркытып тамга салдырдылар хәйләләр илән. Ah, йөз мең каза килгән икән башыма. Шәһид булмай, мондан котылмак юк, башымызга кыямәт йитте. Аллаһы тәбарәкә вә тәгалә тиз үк мөселманлар көтә торган нәрсәләрен биргәй иде. Дивана, көлгән муллалар бу әмерләрне белмәйләр. Әгәр белсәләр иде бу әмерләрне, һәлак булырлар иде хәсрәтләрендин. Тәхкыйк, башымызга кыямәт йитте: мөселманларның куллары багълыдыр, нич нам-нишан юктыр. Аллаһы тәгалә үзе ярдәм бирсен, амин. 1885 нче сәнәдә мартта падишаһ 3 нче министр аркылы губернаторларга боерган зурәлкырайларны* йибәреп, бетерергә мәнегъ кылсын, бездән чара улыпты 1884 нче елдагы миссионер иҗтиһадын йиренә китереңез дип. Бу хосуста губернаторлар участкага бүленгәнләр, поплар тәгаенләнеп беткәнләр, әмма Дине Мөхәммәдиянең Мәхкәмәсенең башы, ягъни мөфти дигән кемсә мәнегъ кылына дип торалар**. Ул Собраниене дә ябылачак дип әйтәләр, шул әмердә имамлык эшләрене бераз мөддәткәчә губернский правлениягә тапшырып, бар мөселман эшләрен тикшерелмәс дигәч, Илаһи, үзең сакла! Ирләр бетте, хатынлар мәнзилендә калды, шул эшләрне белсәләр дә, хамушлардыр, ягъни сөкүт итәләр дип, Духовный собраниядәге сиклатар Попов дигән кемсә министрга агяһландыргандыр. Дәхи мөселманлардан солдатларны кяфер иленә йибәрергә боерган иде. Бу эшләрне, ягъни мәзкүр йортларны салдырыр өчен көчеңез йиткән кадәре бирмәскә тырышыңыз. Урысча укымак хәзер дә бик зарурдыр. Кяфер делендә алданмас өчен һәм аның өчен кәгазен укырга мохтаҗ булып үзенә кол булмас өчен. Мәгәр укыңыз үз йортларыңызда гына, чөнки хәзер дә русча белгән мөселманлар күптер. Әмма мәзкүр ремесленный училище салдырмаска иҗтиһад фарыздыр, чөнки аны салгач да, ишек төбенә бер чиркәү салдырырлар, аңар часовня дип исем бирерләр. Безнең кәгазеземзне губерналарга һәм мәдрәсәләргә вә һәр сәүдәгәрләргә белдереңезләр, хәтта ки белсенләр. Мәзкүр нәрсәләрне ясагач да, мәдрәсәләрне бикләрләр, ягъни бикләнер дигән әмере бар, бер генәсе дә ялган түгел, чөнки Кавказда һәм әрмән халкының мәдрәсәләре бикләнде 85 нче сәнәдә. 90 нчы сәнәдә ибне сәбилдән кемсәнәдән 30 нчы гыйнварда ошбунда мәзкүр хәтәрләр җөмләсендиндер безнең мондагы ахунларның бәгъзесе авылларында булган әһле сиканың бәгъзесенә сиррән шикаять кылмышлар мәхкәмәләрдә өч төрлесен саф эшләрнең улачагы зоһур иттеләр дип. Бере, мөселманларның никахлы зәүҗәсе мәвет улмадыгы хиндә асла фиркать улмаячагы. 2 нче: һичкем бер зәүҗәдән гайре никахланмаячагы, ул бер зәүҗәсе хәят улдыгы мөддәттә. 3 нче: һәркемгә ике исем улачагы, бере мөселманча, бере кәферчә. Әл-гыязе биллаһи тәгалә вә гасманаллаһы тәгалә җәмигыль-мөэминин вәл-мөэминат вәл-мөслимин вәл-мөслимат, амин бихөрмәти сәййидил-мөрсәлин. Вә бәгъдә белмеш уласызлар, кайчан Истанбулга китәргә әмер булган соңында Бакчасарай халкы китәргә кузгала башладылар. Бакчасарайга губернаторлар килгәндә сораган: «Ник китәсезләр, дип, бик ачуланган, под суд ясармын», дигән. Шуның соңында әйткәнләр: «Безләрнең китүемезнең сәбәбе шулдыр: бездән солдат аз алдыңыз, күп алдыңыз, разый булдык, моның соңында урмансыз калдырдыңыз, андын соң килеп җирләремезне кистеңез. Һәрберсен кыскач, үземезне тәрбия кылыр хәлемез юк, шул сәбәпле китәмез», дип җавап биргәнләр, башкасын әйтмәгәнләр.

1864 сәнәсендән 1876 йа кадәр кыргызлар жанирал Кауфман вә әмсале […]*** каршы сөварилекләрне мәйданда исбат итмешләрдер. Екатерина исә бу хәлләре мөляхәза итмеш, фәкать сәясәте дахилия үйлә иҗаб идәрде. Шимде татарлар өчен кыргызлар бәйнендә түгел, дин тәгълиме итмәк өчен тиҗарәт вә башка бер сәнагать бәһанәсилә дәхи карар итмәк катгыйән мәмнүгъдыр. Мәга ма фиһ ихтилат вә галяка көллийән мөнкатыйг уламаз. Екатерина императрицаны татарлар һәр заман йад идәрләр. Бәлки, Екатеринага сәна әйтмәк заманы шимде килмештер. Екатерина әййамыннан соңра унтугызынчы гасыр нисфына кадәр эстәр императорлар тарафыннан, эстәр риҗале хөкүмәт тарафыннан татарлар өчен

* Циркулярларны булса кирәк.
** 1885 елда Казан губернасында округ православие дине миссионерлары штатлары булдырыла, бу урыннарга татарча яки башка жирле халык телен яхшы белүче приход поплары билгеләнә, 1900 елда епархиядә исламга һәм мәҗүсилеккә каршы миссионер штаты булдырыла.
*** Ике сүз аңлашылмый.

EV_1_08.indb 205 13.05.2008 12:20:46

һичбер гүна каләмә алыначак вә яхуд шикаять улыначак бер мөгамәлә күрелмәмештер. Әмма Ауропада исламият галәйһендә, ягъни мөселманнар зарарында бер чук нәшрият гаразкяриләр дәвам идәрәк, сүя ният илә Кәляме кадим Корьән тәржемә вә табыг улынмыш. Вә Кәляме кадимә хосусый канкурдания* — татбикат тәэлиф итмешләр. Библия — Гаһде җәдидләре әлсинәи исламийәйә тәржемә идәрәк, бәйнәл-мөслимин мәҗҗанән нәшер итмешләр. Русиядә бөйлә бер ниййаты фасидәләр әсхабы бик чук күрелмештер. 1846 сәнәдән игътибарән Русиядә дәхи миссионер Гурий (бик алдап эш кылучылар, мәсәләп, хәзерге земский начальник исемендә булганлар, тәгаен шушы адәмләрдер) җәмагаләре зоһур идеп мәсләкләренә мотабикъ китаб тасниф итмешләрсә дә, 1870 сәнәсенә кадәр



Кулъязма прокламациянең бер бите. ТР МА, 1 ф., 6 тасв., 45 эш, 22 кәгазьнең арткы ягы.

матбуг бер рисаләйә тәсадеф улынмамыштыр яхуд надир улыр иде. Император Второй Александр әййамындан игътибарән бер тарафтан миссионерларның күбәюе, дигәр тарафтан сәясәте дахилиянең славян тарафына кәсбе куәт итмәсе мөселманлар галәйһенә бер чук тәфәүвеһата мәйдан ачмыштыр. 1871 сәнәсендән 1886 сәнәсенә кадәр Русиядә исламият галәйһенә нәшер улынан кенәгәләр, китаблар илле дүрт китаб мәнзурым улмыштыр. Бәгъзеләрнең әсамиләрене зирдә ираә идеп, мөәллифләрене дәхи бәян идийурым: «Керәшен татарлары статистикасы», Ефим Малов әсәре, 1866 нчы елда матбуг.

«Керәшен татарлара мөселманларның нөфүзе»**, 1872 нче елда матбугдыр. «Мөхәммәди татарлар илә мөбахәсә ысулы» 1873 нчедә матбуг. Виноградов әсәре.

«Мөселманлара каршы гаһде җәдид гадәме мөхәррәфиятене исбат», 1852 дә тәэлиф, 1874 дә табыг улынмыштыр, Александр Филимонов әсәре.

«Коръәннең хасыйле вә рухы», 1854 дә тәэлиф, 1875 дә табыг улынмыш, Кутивский әсәре.

* Конкорданс булса кирәк.
** Документта: нөфүсе.

EV_1_08.indb 206 13.05.2008 12:20:46

«Мөселманлары нәсраниятә ихраҗ өчен Коръәннән мөнасиб аять». 1844 дә тәэлиф, 1875 дә табыг улынмыш. Фортунатов әсәре.

«Мөхәммәд галәйһис-сәламнең нәсранияттән мәэхүз әфгале». Инглизчәдән тәрҗемә.

«Җиһад хакында мөселманларның тәгълиматы». «Хаҗ вә Мәккәйә сәфәрнең дин вә сәясәтә тәэсире». Бу рисаләдә исламлары мөмкин дәрәҗәдә хаҗдан мәнегъ итмәк өчен мөнасиб тәдабирнең лөзүмене бәян итмеш. Вә бу кеби мөфтәрияты шамил бер чук китаблар вә рисаләләр тәэлиф улынмыштыр вә миссионер җәмагаләре тарафыннан табыг иделәрәк, мөселманлар бәйнендә нәшер улынмакдадыр. Вә бәгъзесе табыг улындыса да, шимделек бер ихтилалы муҗиб улмасын өчен мәхфи тотылмактадыр. Хакыйкатән, бөек мосыйбәттер ки, кемсә дә мөдафәга булынмыйур, бер мөнасиб рәддия күрелмәмештер.

Русиядә исламият галәйһенә мөдахәләи рәсмия

Әүвәлән, мәдарисе исламиянең «Министерство народный просвещения» — мәгариф нәзарәтенә идхал улынмасы. Бу мәсьәлә һәр никадәр мөхтәлифен фиһ исә дә, Сенат мәҗлесендә мөзакәрә улынып, фима бәгъдә гомумән мәдрәсәләре Мәгариф нәзарәтендә булындырмак үзрә карар вирелеп, 1864 сәнәи миладиясендә высочайший повеления — Фәрманы императори садир улдыгы шөбһәсездер. Фәкать сәяси мәэмүрләр ул заманда бу кеби әхвале мәукыйгы ижрайә куймак өчен мөнасиб күрмәмешләр. Чөнки ул заманда нөфүзле* гөләмалар мәүҗүд иде, ихтият итмешләр. Мәга заликә мөселманлар аз булынан вилайәтләрдә мөлайәмәт үзрә мөдахәләйә тәшәббес улынмыш. Ибтидаән Вятка вилаятендә «очередной съезд» мәҗлесендә улан мөслимин русча тәгълименең лөзүмен бәян идеп, «земство» кешеләреннән әгъзаларындан Мирсәед Ягъкуб углы Юнусов мәҗлесә гарыз идәр. Мәҗлес дәхи кабул идәрсә дә, губернский ахунд Ибраһимов мөхаләфәт идәрәк, бу тәдабире фасидәйә мокабил башка бер чара булумаз, «шәригатемез мөсагадә итмийур», диер. Бәгъдәһе мәсьәләне рәсмиятән тәхвил идәрләр. Вятка земский мәҗлесе 1868 сәнәсе 5 нче мартта 1541 номерлы рәсми әүрак илә Духовный собрания мәхкәмәсенә мөрәҗәгать идеп, бер такым рижаларда булыныр. Собрания исә муафәкать күстәрәрәк, җаваб язар вә ахунд Ибраһимовтан объяснения эстәр. 24 апрельдә Вятка валисе тарафыннан дәхи бер кәгазь килер, мөфтинең исламларга нәсыйхәтене рижа идәр. 1 нче июль мөфти рәдде җәмил илә валийә җаваб язар. 7 нче август 68 нче елда Оренбург жанирал-губернаторыннан Духовный собранияйә тәһдиданә бер кәгазь килер. Шул җыл 2 нче сентябрьдә жанирал-губернатора мокабил мәдрәсәләр Собрание нәзарәтендә улмаеп, Мәгариф нәзарәтендә улачагыны бәян итмеш. 12 нче сентябрьдә жаниралы мөшарын иләйһ тәкрар тәһдиданә вә амиранә бер кәгазь язмыш. Боңа мокабил Собраниедә 20 нче сентябрендә журнал илә бер карар үзрә, 30 нчы октябрьдә жаниралы мөшарын иләйһә җаваб язмышлар. Әмма ни гүна җаваб вирелмеш вә ни өчен бу кәгазь карар бәгъдендә Собраниядә бер ай язылмадан калмыш, намәгълүмдер. Вә бәгъдә вилайәт мәхкәмәләре илә Собрания бәйнендә бер чук тәгатые әфкяр әүракы тәдавел итмеш. Муллалар вә әһле бәйнендә дәхи кыйль-каль чук улып, кем русча тәгълим лөзүмене, фәваидене тәгъдад итмеш, вә кем мәзаррәтене санамыш, ләкин асыл төпне, нигезне уйласаң, русча укыганда, дине Мөхәммәди-салләллаһы галәйһи вә сәлләм! — бөтенләй бетәчәк һәм боларның бик зур максудлары да шулдыр. Кәза сәнә 1868 7 нче декабрьдә Сарапул өязе училище мәҗлес мөфти намына махсус кәгазендә 1864 нче сәнәдә 14 нче июльдә садир улмыш әмре императори мужибенчә, татарларны обрусить итмәк, ягъни руслаштырмак өчен гайрәт итмәк сезгә лязимдер, саниян, голямайә «образовательный ценз» тәклиф улынмыш. Бу исә һичбер заман тәҗвиз улынамаз, чөнки имам намаз өчен, моктәдибенә намаз өчен рус лисанының лөзүме һичбер гүна тәэвил улынамаз. Бу эшләрнең лөзүменә биш-алты сәнәләр булды. Имамларның гарәби вә фарсы вә голүме диняне кәма йәнбәгый беләнләре аз калды, хәтта бәгъзеләре көчкә язу таныйлар. Мәга заликә алты-йиде сәнә зарфында бу хәлә кәлделәр. Дәвам идәрсә, кем белер, утыз сәнә соңра ни улырлар. Фикер идәлем, бер имамда әһалийә нөфүз кичерүр,

* Документта: нөфүсле.

EV_1_08.indb 207 13.05.2008 12:20:46

Имам да бу хәлә килерсә, әһали ни улыр. Дине мөбине кем тәгълим идәр? Хакыйкатән, шаяны тәәссеф дәгелме? Янә мөфти хәзрәтләренә игълан итмеш 1870 сәнәсе 18 нче сентябрьдә 66 нчы номерлы әмере яңа мәктәб-мәдрәсә көшадының мәшрутыяте вә сәнәи мәзкүрә 26 нчы март муафикъ низам вә канун улмайан мәдрәсәләре лягу итмәк Мәгариф нәзарәте ихтыярындадыр, кем ни дия белер. Хөкүмәт тарафыннан бу кеби тәкялиф әснасында бәгъзе вилайәт вә нахия мәэмүрләре тарафыннан бер чук тәгаддийат вә тәҗавезат дәхи мәйдана килде, вәхшийанә мөгамәлә улынды. Казанда Мәңгәр вакыйгасы анчак йам йамлардан садир ула белер*. Бер вакыйга кебидер, 1884 тарихында Самарада Сөләй вакыйгасы**, 1893 дә Чистай вакыйгалары*** галәмә тәэсир идәр. Бу вакыйгалар бу эшләрнең әзрәк кичегүенә сәбәп булды.

Бу вакыйгалар булмаганда, шул вакытта тәклиф була иде. Поляклар ялгыз русча укымак илә ни хәлә килделәр. Бүгенге көндә гомум Ләһестанда гыйбадәттән катгы назар илә, гадәте исламиядән дәхи бер шәйләре калмамыш. Татарлар да бонлары һәр заман күрийурлар, әмма һич гыйбрәт алмаслар. «Вә ля тәфәрраку» нассы шәрифене дәрхатыйр идеп, һаман сәгый вә гайрәт итмәле. «Вә ля тәфәрраку» нассы җәлилене һәр кеше фарзы гайн дия игътикад итмәле. Тәвариха бакылырса, һәр милләтнең инкыйразына, һәр дәүләтнең инһидаменә беренче сәбәб тәфәррыкдыр, икенче сәбәб тәфәррыкдыр, өченче сәбәб тәфәррыкдыр. Русия татарларының инкыйразына сәбәбе йәк-дигәрилә бәйнләрендә ля йәнкатыйг дәвам идән гадавәттер, голәма бәйнендә хосумәттер. Голәмамыз бер-берләренә гадавәт вә әмразы шәхсияләрендән ваз кичмәк вә бәйнәл-гавам дәхи хәйсиятьләрене химая идәрәк, фисык вә фәсад вә әхлакы зәмимәдән тәҗәннеб идеп, истикамәт үзрә мәхәллә әһалисенә дөнья вә ахирәтләр өчен нафигъ мохтәсар мәүгазәләр тәлкыйн идәр. [...] Инде бакалымкүрәлем, әгәр дә мәдрәсәләремез ысуле җәдидә илә укытылып, битәдриҗ русча укытыла башласа, безләр дә шул мәзкүр поляклар кеби булуымызда һич шик вә шөбһә улмаячакдыр. Бу әйтелгән эшләр булганда да бик озаклык илә улыр иде. Мөселманларымыз бер иттифакда булып, русларга җул ачып бирмәсәк, әгәр дә мөселманлар иттифаксыз булып, бәгъземез русларга иганә кылып, мөселман кардәшләремезне көчләп, куркытып, руска җул ачып бирсәк, бу эшләр бүген була башлый һәм моның гөнаһысы шул җул күргәзгән мөселманларга булыр, көлле ләгънәт, Алла үзе сакласын. Бу эшләрне, зинһар, пулысында, булган яхшы имамларга, яхшы кешеләргә, зинһар, укытып аңлата күр. Зинһар, саклан, надан мужикларга күрсәтмә, фетнә чыгарырлар. Йа, Рабби, үзең сакла, әмма муллаларга күрсәтеп, алар күргәч, күчереп алмак фарыздыр. […]****

ТР МА, 1 ф., 6 тасв., 45 эш, 11-25 кгз.

---

* Казан губернасында 1878 елның октябрендә таратылган авыл җәмгыятьләренә йөкләү яңа повинностьлар турындагы инструкциянең русларга атап язылган урыннарын (чиркәүләрне төзәтеп тору, училищеларда дин сабагы православие дин әһелләре тарафыннан укытылу һ. б.) мөселманнарга кагылмый дип күрсәтергә оныту күп авыл җәмәгатьләренең хакимият органнары белән араны өзүгә, каршылык күрсәтүгә китерә. Шундый вакыйгаларның берсе Казан өязе Олы Мәңгәр авылында була.

** 1884 елны Самара губерна земствосы «Правила о порядке применения в Самарской губернии меры убивания зачумленного и подозреваемого в зачумлении скота, изданные к обязательному исполнению в Самарской губернии, согласно 6 ст. Закона 3 июня 1879 г.» исемле инстукция кабул итә. «Кагыйдәләрдә» билгеләнгән чаралар авыл җәмгыятьләре хисабына тормышка ашырыла. Шуның өчен һәр хуҗалыктагы мал-туар бәясенең 1,5 % хисабыннан махсус салым кертелә. Инструкция рус крестьяннарын исәпкә алып төзелгән була. Әйтик, анда священниклар турында язылган. Ә мөселман авылларындагы дин әһелләре хакында бер сүз дә әйтелми. Документларны тутыру үрнәкләрендә шулай ук рус авыллары һәм рус кешеләре исемнәре мисалга китерелә. Кайбер мөселманнар кергән участокларга поплар үләт авыруына каршы комиссия вәкилләре итеп билгеләнә һ. б. Ә үләт авыруына каршы көрәшү турындагы татарчага тәржемә ителгән китапчыктан халык малларны үтергәндә аларны мөселманча суеп түгел, ә арт маңгаена укол кадап үтерелүен белеп, бу саклану чарасын татарлар һәм башкортлар мал сую буенча урыс халкы йоласы белән янәшә куеп, шиккә кала. Нәтиҗәдә мөселман авылларында хакимияткә буйсынмау очраклары күзәтелә. 1885 елның 14 апрелендә Самара губернасы Бөгелмә өязе Бигеш авылыннан бер мең чамасы кеше, май аенда Бакай авылы халкы мал-туар арасында таралган үләт авыруына каршы инкяр итеп, полициягә каршылык күрсәтә. 18 майда шул ук өязнең Сөләй авылында 600 татар мал-туарны мәҗбүри страховать итүгә каршы чыга, яңалыкны аңлатырга килгән губернаторга һәм полиция вәкилләренә һөҗүм итә. Декабрь аенда Бөгелмә, Богырыслан, Бузулук һәм Николаев өязләрендәге татарлар һәм башкортлар эпизоотия очракларында мал-туарны үтерүгә каршы чыгалар.

*** 1893 елда Чистай шәһәрендә өлкән яшьтәге ахун Абдулвәһаповның рус телен шәкертләр арасында укытуга каршылыгы нәтиҗәсендә биредәге рус классы укытучысы белән конфликт дин әһелен Себергә сөрү карарын чыгаруга китерә. Сөргеннән ахунны үлеп китүе генә коткара.

**** Документның өченче өлеше төшерелеп калдырылды.

EV_1_08.indb 208 13.05.2008 12:20:47

СҮЗЛЕК:

Агяһ — белеп торучы.
Асла — беркайчан да, һич.
Әййам — көннәр.
Әл-гавам — халык.
Әлсинә — телләр.
Әмраз — авырулар.
Әсами — исемнәр.
Әсна — вакыт.
Әсхаб — ияръчеләр, тарафдарлар.
Әүрак —рәсми кәгазь, хат.
Әфкяр — фикерләр.
Әһле сика — авторитетлы кешеләр.
Батыйл — бозык.
Бәгъзе — кайбер.
Бәйн — ара.
Бәйнендә — арасында.
Бән — мин.
Бәһанәсилә — сылтавы белән.
Бер такым — берничә.
Битәдриҗ — акрынлап.
Вә ля тәфәрраку — бүленмәгез.
Гавам — халык.
Гадавәт — дошманлык.
Гадәд — сан.
Гадәме мөхәррәфият — бозылмаган, үзгәртелмәгән.
Галяка — мөнәсәбәт, элемтә.
Гараз кяри — начар ният белән эшләү.
Гарыз — аңлату.
Гаһде җәдид — яңа васыять.
Гаһед— заман, дәвер.
Гүна — төрле.
Дәрвакыйг — чынлап та.
Дәрхатыйр итү — искә төшерү.
Дине мөбин — хак дин (ислам дине).
Заигъ — әрәм.
Зарф — вакыт.
Заһир — ачык.
Зәмим — начар.
Зәүҗә — хатын.
Зирдә — аста.
Зоһур — беленү.
Ибне сәбил — юлчы.
Ибтидаән — башта.
Игълам — белдерү, аңлату.
Игътибарән — башлап.
Игътикад — ышану.
Идхал — кертү.
Иҗаб — уңай.
Иҗтиһад — тырышу.
Илән — белән.

EV_1_08.indb 209 13.05.2008 12:20:47

Илтизам — мәҗбүр итү.
Инһидам — җимерелү.
Истикамәт — намуслылык.
Ихтилат — аралашу.
Ихтилял — баш күтәрү.
Ихтият — саклык.
Йәк-дигәрилә — бер-берсе арасында.
Касыд — ният, максат.
Катгыйән — тәмам, катгый рәвештә.
Кәза — шул ук.
Кәма йәнбәгый — ничек кирәк, шулай.
Көллийән — тулысынча, бөтенләй.
Көшад — ачылу.
Кыйль-каль — төрлечә сөйләүләр.
Ләгу — бетерү.
Ләкаб — исем, кушамат.
Лисан — тел.
Ля йәнкатыйг — туктаусыз.
Матбуг — басылып чыккан.
Мәвет — үлем.
Мәга заликә — шуның белән бергә.
Мәдарис — мәдрәсә.
Мәҗҗанән — түләүсез.
Мәзаррәт — зарар.
Мәзкүр — югарыда әйтелгән.
Мәмнүгъ — тыелган.
Мәнзил — урын.
Мәнзур — күрелгән.
Мәнегъ — киртә.
Мәсләк — дөньяга караш.
Мәукыйгы иҗрайә кую — тормышка ашыру.
Мәүҗүд — бар.
Мәхкәмә — суд.
Мәхфи — яшерен.
Мәшрутыят — шартлылык.
Мәэмүр — чиновник.
Мокабил — каршы.
Моктәдиб — иярүче.
Мосыйбәт — кайгы.
Мотабикъ — туры килгән.
Мохтәсар — кыска.
Мөәллиф — язучы.
Мөдафәга — каршылык күрсәтү.
Мөдахәлә — тыкшыну, кысылу.
Мөддәт — вакыт.
Мөзакәрә — фикер алышу.
Мөкаддәм — әүвәл, алда.
Мөлайәмәт — йомшак.
Мөляхәза — фикер йөртү.
Мөнасиб — яраклы.
Мөнкатыйг — киселгән.
Мөсагадә — ярдәм итү.

EV_1_08.indb 210 13.05.2008 12:20:47

Мөсәлләм — инкяр ителми торган, канәгать.
Мөфтәрият — яла ягулар.
Мөхаләфәт — каршы килү.
Мөхтәлифен фиһ — каршылыклы.
Мөшарын иләйһ — югарыда күрсәтелгән.
Муҗиб — барлыкка китерүче.
Надир — сирәк.
Наиб — урынбасар.
Нам — исем.
Нассы шәриф, нассы җәлил — дәлил буларак китерелгән Коръән аяте.
Нафигъ — файдалы.
Нәсрани — христиан.
Нәшер — тарату.
Ниййаты фасидә — бозык ниятләр.
Нисыф — ярты.
Нишан — билге.
Носрәт — ярдәм.
Нөфүз — абруй, йогынты.
Пулыс — волость.
Рәдд — кире кагу.
Рәддия — берәр фикерне кире кагуга багышланган язма хезмәт.
Рижа — үтенү.
Рижале хөкүмәт — хөкүмәт әгъзалары.
Садир — чыккан.
Саниян — икенчедән.
Сәгый — тырышлык.
Сәна — мактау сүзләре.
Сиклатар — секретарь.
Сиррән — яшерен рәвештә.
Сөварилек — егетлек.
Сөкүт — дәшми тору.
Сүэ — явыз.
Тасниф — китап язу.
Татбикат — туры китереп.
Тәварих — тарихи язмалар.
Тәгаенләнгән — билгеләнгән.
Тәгатый — кара-каршы бирешү.
Тәгаддийат — дошмани гамәлләр.
Тәгъдад — санау.
Тәдабир — чаралар.
Тәдавел — әйләнеш.
Тәдбир — тиешле чара.
Тәжавезат — чиктән чыгу.
Тәжәннеб — качу, китү.
Тәжвиз — хуплау.
Тәклиф — әмер, боеру.
Тәкялиф — боерулар.
Тәлкыйн — аңлату.
Тәнбиһ — кисәтү, искәртү.
Тәсадеф — очрашу.
Тәфәррык — аерылу.
Тәхвил — күчерү.

EV_1_08.indb 211 13.05.2008 12:20:47

Тәхкыйк — дөрес.
Тәхте тәсаррыфына — кулы астына.
Тәһдиданә — куркыта торган.
Тәшәббес — күрешү, тотыну.
Тәэвил — аңлату.
Тәәссеф — кызганыч.
Тәфәүвеһат — имеш-мимешләр.
Тиҗарәт — сату.
Фарзы гайн — шәригать буенча һичшиксез башкарылырга тиешле гамәлләр.
Фасидә — бозык.
Фәваид — файдалар.
Фәсад — бозыклык.
Фима бәгъдә — шуннан соң.
Фиркать — аерылышу.
Фисык — начар юлга керү.
Хамуш — дәшмәүче.
Хасс — югары катлау.
Хәйсият — дәрәҗә, тоткан урын.
Хәражат — чыгымнар.
Химая — саклау, яклау.
Хин — вакыт.
Хосумәт — дошманлык.
Һибә — бүләк.
Шамил — эченә алган.
Шаян — тиешле.
Шәй — әйбер.
Шимде — хәзер.

Документны басмага
тарих фәннәре кандидаты
Лилия Байбулатова
әзерләде

РЕЗЮМЕ
Публикация И. Загидуллина и Л. Байбулатовой посвящена антиправительственному татарскому национальному движению последней четверти XIX в., направленному против вмешательства властей в жизнь мектебе и медресе, систему конфессионального образования, против распространения русского образовательного ценза для кандидатов на духовные должности. Особенностью движения стало появление рукописных прокламаций, авторы которых стремились со своей точки зрения объяснить единоверцам суть внутриполитического курса самодержавия в отношении мусульман. Сокращенный текст одной из таких рукописных прокламаций представлен вниманию читателей.

EV_1_08.indb 212 13.05.2008 12:20:47